

Сания Чинакаева ВКонтакте битендə болай ди: «Хəерле кон. Без Фəридə Хəсəновнаны белəбез, Вачевкада 20 елдан артык яшəмəсəк тə. Мин тумышым белəн Темников районыннан, бvген Питерда яшибез. Əти-əнилəребез янына Вачеевка авылына килгəч, кибеткə йори идек. Ул бик яхшы сатучы, акыллы, чисталыкны ярата, кибеттə һəрчак тəртип була иде. Ярдəмчел, товары турында һəрвакыт əйтеп бирə, нəрсəгə кирəклеген дə анлата.      Ходай ана сəламəтлек, унышлар бирсен. Анын турында «Ельниковская трибуна» газетасына язганнары очен зур рəхмəт; ул мона vз хезмəте белəн лаек.»Берничə кон элек кулланучылар коо-перациясенен ин олкəн хезмəткəрлəрен-нəн берсе Фəридə Хəсəн кызы Богдановага житмеш яшь тулды. Аны бу дата белəн котларга хезмəттəшлəре О.И.Балаева белəн Н.И.Салаева килгəн иделəр. Ольга Ивановна, Ельники райпосы профкомы рəисе буларак, туган конен билгелəп vтvче Фəридə апага бик кvп жылы сvзлəр əйткəн: «Бvген Фəридə Хəсəновна районнын кулланучылар кооперациясе системасында ин олкəн сатучы. Остəвенə, һонəренə тугры калып, бvген дə эшли. Һəм, минемчə, эш акчада тvгел, ə сайлаган һонəренə мəхəббəттə; ул ана 45 елдан артык гомерен багышлаган.»

Фəридə апа Богданова яши торган Вачеевка авылы Ельники районындагы кечкенə генə торак пункт. Халкын бармак белəн генə санарга момкин. Ə менə сəвдə ноктасы, барлык авырлыкларга карамастан, бvгенге конгə кадəр эшли, чонки анда сатучы – Фəридə Хəсəн кызы бар. Кvршелəрдəге Новоямская Слобода, Новоникольское, Новый Ковыляй кебек зур торак пунктлардагы кvп кенə кибетлəрдə кvптəн кадрлар житми, ə Вачеевка кибете ишеге һəрвакыт ачык. Кибеттə халык телəген тəэмин итəрлек товарлар бар: кирəкле продуктлар һəм товарлар Ф.Х.Богданова заявкасы буенча кайтарыла.

Якын-тирə торак пунктларда яшəvчелəр, ə бу, нигездə, олкəн яшьтəге кешелəр, сатучынын тырышлыгы очен ана рəхмəтлелəр.

Язма героебыз турында берничə сvз. Ул vз юлын кечкенə кызчык буларак сайлаган: иптəшлəре белəн бергə (ə алар ике дистə-дəн артык кеше жыелган) сигезенче сыйныфны темамлагач, Саранск кооператив училищесына укырга керергə карар кылган. Барлык абитуриентлар арасыннан укырга ул ялгызы кала. Дуслары, торле сəбəплəр табып, курстан китеп барганнар. Бəлки, ул да киткəн булыр иде, əмма əти-əнисе һəм ике туганнан туган абыйсы кызнын училищены тəмамлавын талəп иткəннəр; шуна ул бу уку йортын тəмамлаган.

Белгəнебезчə, беренче эш коне һəм беренче эш урыны һəрвакыт хəтердə уелып кала. Анын – Ликенье авылы. Голландкалы кечкенə кирпеч бина. Торле яшьтəге сатып алучылар, кvпчелек очракта - танышлар, кайбер туганнары, яшь кибетче кызны ачык йоз

белəн каршы алганнар. Кыскасы, хезмəткəргə кем эш белəн, кем сvз белəн ярдəм итə шул вакыт. Бу елларда кvчмə сəvдə прилавкалары кvп кенə хезмəткəр очен эшенен аерылгысыз бер олеше булып саналган. Менə Фəридə дə районындагы Сузеляткага, Коринога, Старые Шалыга сəvдə итəргə чыга торган булган. Сатудан башка, капчыктагы тоз-ярмаларны һəм каробкалардагы башка товарларны автолавкага тояп жибəрергə, ə кичен бушатырга vзенə туры килгəн. Шул сəяхəтлəрдəн сон ул оенə арып кайта торган булган, ə ойдə- гаилə, хужалык. Бvген дə Фəридə Хəсəн кызы ярдəмнəре очен əнисе Өйшə Садретдин кызы Кремчееваны һəм кайнанасы Маһинур Хəлим кызы Богданованы рəхмəт сvзлəре белəн искə ала.
Фəридə Хəсəн кызы Богданова Ликень-еда ун  ел эшли. Тəжрибə тупладым, отчет тозергə ойрəндем, кvп кенə авыл ке шелəренен гореф-гадəтлəрен һəм их-тыяжларын белдем, дип истəлеклəрен янарта ул. Тик менə туксанынчы еллар килеп житə. Ликенье авылындагы кибет, рентабельле булмавы аркасында, ябыла. Аны ябалар, ə  сатучы Фəридə Хəсəновнаны Лобановка авылына кvчерəлəр. Һəрва-кыттагыча эш урынына кадəр хатын жəяv йори. Хəер, ара ерак тvгел. Кайчагында авылдашлары яки туганнары эшкə кадəр машинада алып барганнар, əмма бу бик сирəк булган.
- Лобановка авылында мин бераз эш-лəдем, - дип сойли юбиляр. - Өмма бу бик авыр еллар иде. Ярмалар, шикəр талон буенча бер кешегə 300 граммнан жибəрелə иде. Шырпы, сабын да талонга иде. Яхшысы-яманы белəн бу еллар да vтə. Аннары Фəридə Хəсəн кызы Богданова Вачеевка авылындагы гади авыл оендəге кибеткə килə. Вакыт тозелешкə vз эзен сала һəм ул елдан-ел искереп, тузып бетə. Хатын əле яна сəvдə ноктасы тозv турында сорап партия райкомы, район кулланучылар жəмгыяте идарəсе бусагаларын бер генə тапкыр йореп чыкмый. Бу иске кибеттə эшлəп булмагач, югары инстанциялəр рохсəте белəн, биш ел оендə сəvдə итə. Шулай да башлаган эшенен матур чишелешенə ирешə ул. 2011 елнын козендə Вачеевкада яна кибет ачыла: прилавка артында - таныш кеше.
Кvпьеллык һəм мактауга лаеклы хезмə-те очен Фəридə Хəсəн кызы Богданова Мордпотребсоюздан медальлəр ала, шулай ук «Хезмəт ветераны» исеменə ия. Анын эшендə һəрвакыт кызлары - əти-əнилəреннəн ерак тvгел яшəvче Галия белəн Халидə ярдəм итəргə əзер. Фəридə əбилəренен даими кунаклары - дvрт кыз оныгы һəм бер малай оныгы. Бер правнучкасы да бар.
Үз һонəренə тугры кешелəрне хəзер табу кыен. Балалары, оныклары кайгыртучанлы-гы һəм хормəте белəн уратылган Фəридə Хəсəн кызы Богданова бvген дə рəхəтлəнеп эшли; Ельники районы кулланучылар жəм-гыяте житəкчелеге һəм авылдашлары арасында мактаулы урын алып тора.

**Наилə НАСЫРОВА**